КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 декабрь г.Казань № 1082

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 17 май, 327 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 май, 300 нче; 2015 ел, 15 сентябрь, 679 нчы; 2016 ел, 6 сентябрь, 615 нче; 2016 ел, 19 декабрь, 951 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә һәм 1 пунктта «китапханәләреннән» сүзен «китапханәләр» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

исемендә һәм I бүлекнең беренче абзацында «китапханәләреннән» сүзен «китапханәләр» сүзенә алмаштырырга;

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең хокукый нигезе

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив хокукый актлар, методик, инструктив һәм гамәлгә кую документлары белән регламентлана:

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Граждан кодексы;

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Россия Федерациясенең мәдәният турында законнары нигезләре» 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында»1994 елның 29 декабрендәге 77-ФЗ номерлы Федераль Закон;

«Китапханә эшчәнлеге турында» 1994 елның 29 декабрендәге 78-ФЗ номерлы Федераль Закон;

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль Закон;

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль Закон;

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Балаларны сәламәтлекләренә һәм үсешләренә зыян китерүче мәгълүматтан саклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль Закон;

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлыФедеральн закон;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеген, «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация сыйфатламалары» бүлеген раслау хакында» 2011 ел, 30 март, 251н боерыгы;

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Китапханәләр фонды составына кергән документларны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2012 ел, 8 октябрь, 1077 нче боерыгы;

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт һәм муниципаль архивлардагы, музейларда һәм китапханәләрдә, Россия фәннәр академиясе оешмаларындагы башка архив документларын саклауны, комплектлауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2007 ел, 18 гыйнвар,  19 нчы боерыгы;

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Китапханәләрдә башкарыла торган эшләргә хезмәтнең типик тармак нормаларын раслау турында» 2014 ел, 30 декабрь, 2477 нче боерыгы;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре турында һәм Татарстан Республикасында башка телләр хакында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасында китапханәләр һәм китапханә эше турында» 1998 елның 21 октябрендәге 1818 номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасы документларының түләүсез мәҗбүри нөсхәсе турында» 2005 елның 18 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру хакында» 1999 ел, 10 декабрь, 813 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

локаль акт белән расланган китапханә уставы;

билгеләнгән тәртиптә расланган китапханә эшчәнлеген регламентлый торган локаль актлар.»;

XII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«XII. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартын сакламауга шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карап тикшерү тәртибе

12.1. Шикаять китапханәгә язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Китапханә җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына бирелә.

12.2. Китапханә, китапханә җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр почтадан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, китапханәнең рәсми сайты, Россия Федерациясе дәүләт хезмәтләре бердәм порталы (www.gosuslugi.ru) яисә Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша җибәрелә ала, шулай ук гариза бирүче шәхсән тапшырганда кабул ителә ала.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

12.4. Китапханәгә, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына кергән шикаять аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, ә китапханә гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга шикаять биргән очракта яисә әлеге төзәтмәләргә куелган вакытны бозуга шикаять биргән очракта – теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә.

12.5. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм, аны кабул иткән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында язмача һәм гариза бирүче теләге буенча – электрон формада дәлилләнгән җавап җибәрә.

12.6. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган бозуларны кичектергесез бетерү максатында китапханә гамәлгә ашыра торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен алу өчен алга таба эшләргә кирәкле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатулар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки нәтиҗәләре буена административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичектермичә прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирә ала.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Музей предметларын, музей коллекцияләрен халыкка күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 1 ноябрь, 832 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 6 сентябрь, 615 нче; 2018 ел, 9 июнь, 441 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган музей предметларын, музей коллекцияләрен халыкка күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 бүлекне түбәндге редакциядә бәян итәргә:

«12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартын сакламауга шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карап тикшерү тәртибе

12.1. Шикаять учреждениегә язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Учреждение житәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына бирелә.

12.2. Учреждение, учреждение җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр почтадан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, китапханәнең рәсми сайты, Россия Федерациясе дәүләт хезмәтләре бердәм порталы (www.gosuslugi.ru) яисә Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша җибәрелә ала, шулай ук гариза бирүче шәхсән тапшырганда кабул ителә ала.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

12.4. Учреждениегә, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына кергән шикаять аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, ә учреждение гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга шикаять биргән очракта яисә әлеге төзәтмәләргә куелган вакытны бозуга шикаять биргән очракта – теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә.

12.5. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы

законнар нигезендә карар кабул итә һәм, аны кабул иткән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында язмача һәм гариза бирүче теләге буенча – электрон формада дәлилләнгән җавап җибәрә.

12.6. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган бозуларны кичектергесез бетерү максатында учреждение гамәлгә ашыра торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен алу өчен алга таба эшләргә кирәкле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул  ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатулар, шулай ук кабул ителгән карарга  шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки нәтиҗәләре буена административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичектермичә прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирә ала.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартларын раслау турында» 2018 ел, 31 май, 409 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартының 12 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Әлеге стандартын сакламауга шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карап тикшерү тәртибе

12.1. Шикаять Оешмага язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Китапханә җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына бирелә.

12.2. Оешма, Оешма җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр почтадан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, китапханәнең рәсми сайты, Россия Федерациясе дәүләт хезмәтләре бердәм порталы (www.gosuslugi.ru) яисә Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша җибәрелә ала, шулай ук гариза бирүче шәхсән тапшырганда кабул ителә ала.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

12.4. Оешмага, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына кергән шикаять аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, ә китапханә гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга шикаять биргән очракта яисә әлеге

төзәтмәләргә куелган вакытны бозуга шикаять биргән очракта – теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә.

12.5. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм, аны кабул иткән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында язмача һәм гариза бирүче теләге буенча – электрон формада дәлилләнгән җавап җибәрә.

12.6. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган бозуларны кичектергесез бетерү максатында Оешма гамәлгә ашыра торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен алу өчен алга таба эшләргә кирәкле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул  ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатулар, шулай ук кабул ителгән карарга  шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки нәтиҗәләре буена административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичектермичә прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирә ала.».

әлеге карар белән расланган Кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартының 12 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартын сакламауга шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карап тикшерү тәртибе

12.1. Шикаять Оешмага язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Оешма җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына бирелә.

12.2. Оешма, оешма җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр почтадан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, китапханәнең рәсми сайты, Россия Федерациясе дәүләт хезмәтләре бердәм порталы (www.gosuslugi.ru) яисә Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша җибәрелә ала, шулай ук гариза бирүче шәхсән тапшырганда кабул ителә ала.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

12.4. Оешмага, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына кергән шикаять аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, ә китапханә гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга шикаять биргән очракта яисә әлеге

төзәтмәләргә куелган вакытны бозуга шикаять биргән очракта – теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә.

12.5. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм, аны кабул иткән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында язмача һәм гариза бирүче теләге буенча – электрон формада дәлилләнгән җавап җибәрә.

12.6. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган бозуларны кичектергесез бетерү максатында Оешма гамәлгә ашыра торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен алу өчен алга таба эшләргә кирәкле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатулар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки нәтиҗәләре буена административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичектермичә прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирә ала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин